РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.09.2024 Буа шәһәре №256/Бк/к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Дельфин» спорткомплексы МБУ тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2024 елның 02 февралендәге 15/Бк/к номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (06.06.2024 елның 158/Бк/к номерлы редакциясендә)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ :**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Дельфин» спорткомплексы МБУ тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2024 елның 02 февралендәге 15/Бк/к номерлы карарына (06.06.2024 елның 158/Бк/к номерлы редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (1 нче кушымта).

1.2. 2024 елның 06 июнендәге 158/Бк/к карарына кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә (http://pravo.tatarstan.ru/), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш (http://buinsk.tatarstan.ru).

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л. Н.Садретдиновага йөкләргә.

Җитәкче Л.Р.Шакирҗанов

кушымта

**«Дельфин» спорткомплексы МБУ тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтүгә тарифлар**

| № | Хезмәтләр исеме | Үлчәү берәмлеге | Хезмәт бәясе, сумнарда |
|---|---|---|---|
| | **Бассейнда булу вакыты** | 1 сәгать | |
| 1 | Бассейнга бер тапкыр бару: | | |
| | - өлкәннәр өчен | 1 сәгать | 200 |
| | - балалар өчен (16 яшькә кадәр) | 1 сәгать | 100 |
| | студентлар өчен | 1 сәгать | 150 |
| | - яшь буенча пенсионерлар өчен (хатын-кызлар 60 яшь+, ирләр 65 яшь+), пенсия таныклыгы биргәндә, көн саен күпләп йөзү 08.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр. | 1 сәгать | 180 |
| 2 | Бассейнга бару өчен абонемент билеты бәясе (8 тапкыр килү): | 8 тапкыр килү | |
| | - өлкәннәр өчен | 1 сәгать | 1400 |
| | - балалар өчен (16 яшькә кадәр) | 1 сәгать | 700 |
| | - студентлар өчен | 1 сәгать | 1050 |
| 3 | Инструктор белән йөзәргә өйрәтү | 45 мин | 350 |
| 4 | Балалар өчен «Йөзәргә өйрәнәм» төркеме | 45 мин<br>1 ай (12 тапкыр килү) | 100<br>1100 |
| 5 | Аква-аэробика | 45 мин | 300 |
| 6 | Аква-аэробика өчен абонемент билеты бәясе (8 тапкыр килү) | 8 тапкыр килү | 2100 |
| 7 | Бассейн бирү хезмәте (1-30 кеше) | 1 сәгать | 6000 |
| 8 | Гаилә саунасына бер тапкыр бару (4 кешегә, аннан соңгы һәркайсы өчен +200 сум) | 1 сәгать | 900 |
| 9 | Прокат (йөзү өчен башлыклар, башмаклар, түгәрәкләр (балалар өчен) | 1 сәгать | 50 |
| 10 | Солярий | 1 минут | 50 |
| 11 | Массаж креслосы хезмәтләре | 20 минут | 100 |
| 12 | Трактор хезмәтләре | 1 сәгать | 2500 |
| 13 | 1 нче номерлы Люкс кунакханә номеры | 1 кеше | 1200 |
| 14 | 2 нче номерлы кунакханә номеры | 1 кеше | 800 |
| 15 | Мәктәп яны җәйге лагерьларыннан, «Бор», «Чайка» сәламәтләндерү лагерьларыннан балаларның бассейнга килүе | 1 сәгать | 100 |
| | **Ташламалар:** | 1 сәгать | |
| 16 | Инвалид балаларның бассейнга баруы (атнага 1 тапкыр ) | 1 сәгать | Түләүсез |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 17 | Махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының бассейнга баруы | 1 сәгать | Түләүсез |